КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 24 июль г.Казань № 588

«Милли сәүдә маркасы» мәгълүмат билгесен куллану хокукын алу һәм аннан мәхрүм итү тәртибен, шулай ук «Милли сәүдә маркасы» мәгълүмат билгесен куллану хокукын алуга карата таләпләрне раслау турында

«Татарстан Республикасында азык-төлек продуктларының сыйфатын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча аерым чаралар турында» 2016 елның 17 ноябрендәге ТРЗ-82 номерлы Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән «Милли сәүдә маркасы» мәгълүмат билгесен куллану хокукын алу һәм аннан мәхрүм итү тәртибен, шулай ук «Милли сәүдә маркасы» мәгълүмат билгесен куллану хокукын алуга карата таләпләрне расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министр А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 24 июль, 588 нче
карары белән расланды

# «Милли сәүдә маркасы» мәгълүмат билгесен куллану хокукын алу һәм аннан мәхрүм итү тәртибе, шулай ук «Милли сәүдә маркасы» мәгълүмат билгесен куллану хокукын алуга карата таләпләр

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Тәртип һәм таләпләрдә «Милли сәүдә маркасы» мәгълүмат билгесен куллану хокукын алу һәм аннан мәхрүм итү механизмын, шулай ук «Милли сәүдә маркасы» мәгълүмат билгесен (алга таба – мәгълүмат билгесе) куллану хокукын мәгълүмат билгесен куллану хокукын алуга дәгъва итүче юридик затлар һәм индивидуаль эшмәкәрләр (алга таба – Гариза бирүчеләр) тарафыннан алуга карата таләпләрне билгели.

1.2. Мәгълүмат билгесен куллану хокукы азык-төлек продукциясенең һәр ассортимент төркеменә (яки аерым исеменә) түләүсез нигездә бирелә, азык-төлек продукциясенә карата мәгълүмат билгесен һәм мәгълүмат билгесенең сүз атамасын куллану хокукын бирү турында гариза (алга таба – гаризада күрсәтелгән азык-төлек продукциясе, гариза) тапшырыла.

## 2. Мәгълүмат билгесен куллану хокукын алуга карата таләпләр һәм аны алу тәртибе

2.1. Гариза бирүчеләр түбәндәге мәҗбүри шартларны үтәгәндә мәгълүмат билгесен куллану хокукын алуга дәгъва итәргә мөмкин:

гаризада күрсәтелгән азык-төлек продукциясен җитештерү Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашырылырга тиеш;

гаризада күрсәтелгән азык-төлек продукциясен җитештерү бары үз илебез чималыннан һәм (яки) Таможня берлеге илләрендә (җитештерү технологиясе бары Таможня берлегеннән читтә җитештерелә торган төп булмаган компонентларны күздә тоткан очраклардан тыш) җитештерелгән чималдан гамәлгә ашырыла;

азык-төлек продукциясен мәгълүмат билгесе белән маркировкалау халыкка бу азык-төлек продукциясенең норматив документларда билгеләнгән азык-төлек продукциясенең сыйфатына һәм куркынычсызлыгына карата таләпләргә җавап бирүе, чимал компонентлары составы һәм нормалары буенча Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында хәбәр итә;

чыгарыла торган азык-төлек продукциясенә ярлыклар, этикеткалар, тәгълимнамәләр (булган очракта) Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә языла;

Гариза бирүче тарафыннан Таможня берлегенең гаризада күрсәтелгән азык-төлек продукциясенә гамәле кагыла торган гамәлдәге техник регламентларын үтәү.

Яклар килешүе буенча Гариза бирүче гаризада күрсәтелгән азык-төлек продукциясенең җитештерү стандартларына туры килү-килмәвен тикшерү, аңа лаборатория анализлары ясау һәм аның сыйфатына башка тикшерүләр (алар нигезендә ирекле формада тутырылган актка имза куела) үткәрү өчен «Милли сәүдә маркасы» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе вәкилләренең предприятиегә үтеп керүен тәэмин итүгә ирекле формада язма ризалык бирә. Тикшерү нәтиҗәләре буенча мәгълүмат билгесен кулланууны туктату яки алга таба куллану турында карар кабул ителә.

Мәгълүмат билгесен куллану хокукын алу өчен Гариза бирүче «Милли сәүдә маркасы» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесенә бу Тәртип һәм таләпләргә теркәлгән 1 нче кушымтада бирелгән форма буенча гариза тапшыра һәм түбәндәге документларны кертә:

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан (Индивидуаль эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан) өземтә;

ярашлылык сертификатлары һәм (яки) ярашлылык турында декларацияләр күчермәләре, Россия Федерациясе территориясендә беренче тапкыр җитештерелә торган махсуслаштырылган азык-төлек продукциясенә яки азык-төлек продукциясенә дәүләт теркәве турында таныклык, хайваннан алынган эшкәртелмәгән азык-төлек продукциясенә ветеринария таныклыгы;

Гариза бирүченең гаризада күрсәтелгән азык-төлек продукциясен җитештерүне Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыру турындагы язма раслау кәгазе (ирекле формада);

Гариза бирүченең гаризада күрсәтелгән азык-төлек продукциясен җитештерүне бары үз илебез чималыннан һәм (яки) Таможня берлеге илләрендә җитештерелгән чималдан гамәлгә ашыру турындагы язма раслау кәгазе (ирекле формада);

төп параметрларның һәм күрсәткечләрнең микъдари мәгънәләрен Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә күрсәтеп, гаризада күрсәтелгән азык-төлек продукциясенең төп куллану үзенчәлекләре тасвирламасы, исеме (ирекле формада);

Гариза бирүче тарафыннан җитештерелә торган азык-төлек продукциясенең һәр ассортимент төркеменә (яки аерым атамасына) гариза языла;

документларның күчермәләре Гариза бирүче тарафыннан раслана, ул бирелгән мәгълүматларның дөреслеге өчен җавап бирә;

мәгълүмат билгесен куллану хокукын алу өчен Гариза бирүче азык-төлек продукциясенең сыйфатын һәм аның төрү материалын бәяләү өчен «Милли сәүдә маркасы» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесенә продукция үрнәкләрен тапшыра.

2.2. Гариза бирүче тарафыннан тапшырылган һәм бу Тәртип һәм таләпләрнең 2.1 нче пунктында күрсәтелгән документлар аларны кабул итү көне турындагы билгесе булган опись белән кабул ителә, алар гаризаларны теркәү журналында кергән көндә теркәлә һәм кире кайтарылмый. Гариза тапшырылган вакыттан ике айдан да соңга калмыйча карала.

2.3. Мәгълүмат билгесен куллану хокукын бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

гаризада күрсәтелгән азык-төлек продукциясенең бу Тәртип һәм таләпләрнең 2.1 нче пунктында билгеләнгән мәҗбүри шартларга туры килмәве;

Гариза бирүче тарафыннан бу Тәртип һәм таләпләрнең 2.1 нче пунктында күрсәтелгән документлар тапшырылмаган яки тулы күләмдә тапшырылмаган булу (тапшырылуы мәҗбүри булмаган документлардан тыш);

Гариза бирүче тарафыннан дөрес булмаган мәгълүматлар тапшырылу.

2.4. Мәгълүмат билгесен куллану хокукын бирүдән баш тарту турындагы мәгълүмат Гариза бирүчегә мондый карар кабул ителгән вакыттан биш эш көне эчендә, кабул ителгән карарның нигезләрен күрсәтеп, почта элемтәсе оешмасы аша хәбәрнамә кәгазе булган заказлы хат җибәрү юлы белән хәбәр ителә.

2.5. Мәгълүмат билгесен куллану хокукын бирү турындагы карар түбәндәге шартлар булганда кабул ителә:

гаризада күрсәтелгән азык-төлек продукциясе бу Тәртип һәм таләпләрнең 2.1 нче пунктында билгеләнгән мәҗбүри шартларга туры килгәндә;

Гариза бирүче тарафыннан бу Тәртип һәм таләпләрнең 2.1 нче пунктында күрсәтелгән документлар тулы күләмдә тапшырылганда.

2.6. Мәгълүмат билгесен куллану хокукын бирү турында карар кабул ителгән вакыттан 10 эш көне эчендә «Милли сәүдә маркасы» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе һәм Гариза бирүче арасында мәгълүмат билгесен куллану хокукын бирү турында шартнамә төзелә.

2.7. Шартнамә төзелгән вакыттан 10 эш көне эчендә «Милли сәүдә маркасы» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе Гариза бирүчегә бу Тәртип һәм таләпләргә теркәлгән 2 нче кушымтада бирелгән форма буенча мәгълүмат билгесен куллану хокукын бирү турында таныклык бирә.

## 3. Мәгълүмат билгесен куллану хокукы гамәлдә булу вакытын туктату һәм озайту, мәгълүмат билгесен куллану хокукыннан мәхрүм итү

3.1. Мәгълүмат билгесен куллану хокукы өч елга бирелә.

3.2. Мәгълүмат билгесен куллану хокукы гамәлдә булу вакытын озайту әлеге хокукны алу өчен билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

3.3. Юридик затны үзгәртеп оештырган, бетергән, аның исемен үзгәрткән, индивидуаль эшмәкәр эшчәнлеген туктаткан очракта, мәгълүмат билгесен куллану хокукы юридик затны үзгәртеп оештыру, бетерү, аның исемен үзгәртү, индивидуаль эшмәкәр эшчәнлеген туктату вакытыннан туктатыла.

3.4. Гариза бирүче түбәндәге очракларда мәгълүмат билгесен куллану хокукыннан әлеге хокук бирелгән вакыт чыкканга кадәр мәхрүм ителергә мөмкин:

халыкның санитария-эпидемиологииия иминлеге өлкәсендә административ хокукларны бозган, кулланучылар хокукларын яклау өлкәсендә административ хокукларны бозган, гаризада күрсәтелгән азык-төлек продукциясенә карата техник регламент таләпләрен бозган өчен Гариза бирүчене календарь ел дәвамында өч тапкырдан күбрәк административ җаваплылыкка тартканда;

Гариза бирүче тарафыннан мәгълүмат билгесен куллану хокукы өченче затларга тапшырылганда;

гаризада күрсәтелгән азык-төлек продукциясе бу Тәртип һәм таләпләрнең 2.1 нче пунктында билгеләнгән мәҗбүри шартларга туры килмәгәндә;

мәгълүмат билгесен хокуксыз урнаштырганда.

3.5. Мәгълүмат билгесен куллану хокукыннан мәхрүм итү турында карар Азык-төлек продуктларының сыйфатын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү мәсьәләләре буенча ведомствоара яраштыру советы тарафыннан кабул ителә һәм әлеге советның утырышта катнашучы барлык әгъзалары имзасын куя торган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

3.6. Азык-төлек продуктларының сыйфатын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү мәсьәләләре буенча ведомствоара яраштыру советының Гариза бирүчене мәгълүмат билгесен куллану хокукыннан мәхрүм итү турындагы карары мәгълүмат билгесен куллану хокукын бирү турындагы шартнамәне берьяклы тәртиптә өзүгә нигез була.

3.7. Бу Тәртип нигезләмәләренең һәм таләпләрнең үтәлеше өчен Гариза бирүче җавап бирә.

«Милли сәүдә маркасы» мәгълүмат билгесен куллану хокукын алу һәм аннан мәхрүм итү тәртибенә, шулай ук «Милли сәүдә маркасы» мәгълүмат билгесен куллану хокукын алуга карата таләпләргә 1 нче кушымта

«Милли сәүдә маркасы»
мәгълүмат билгесен куллану хокукын алу турында
гариза

Гариза бирүче ___________________________________________________________
(оештыру-хокук формасы, тулы һәм кыскартылган исеме − юридик зат өчен;
фамилиясе, исеме, атасының исеме – индивидуаль эшмәкәр өчен)

______________________________________________________________________
_________________________________________________________________ йөзендә
(вазыйфаның исеме, фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) − юридик зат өчен)
юридик адресы: _______________________________________________________,
(юридик зат өчен)
факттагы адресы: _____________________________________________________,
(юридик зат, индивидуаль эшмәкәр өчен)
почта адресы: ________________________________________________________,
(юридик зат, индивидуаль эшмәкәр өчен)
паспорт: сериясе ________ номеры ___________ ____________________________
(индивидуаль эшмәкәр өчен)
________________________________________________________________ бирелде,
(кем тарафыннан бирелгән, бирү көне)
телефоны __________________ факсы ___________________ E-mail: _____________,
______________________________________________________________________
(азык-төлек продукциясенең ассортимент төркеме (яки аерым атамасы),
____________________________________________________________________ га
азык-төлек продукциясенең исеме)

«Милли сәүдә маркасы» мәгълүмат билгесен куллану хокукын бирүне сорыйм.

Гариза бирүче «Милли сәүдә маркасы» мәгълүмат билгесен куллану хокукын бирү таләпләре һәм тәртибе белән таныштым һәм риза булды.

Гаризага _____ биттә документлар теркәлә.

Моның белән «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 ел, 27 июль, ФЗ-152 нче Федераль закон нигезендә минем шәхси мәгълүматларымны эшкәртүгә ирекле язма ризалыгымны бирәм.

Гариза бирүче ____________________ (______________________________)
(имза) (имза тулысынча)

Мөһер булганда
«____» _______________ 201_ ел

«Милли сәүдә маркасы» мәгълүмат билгесен куллану хокукын алу һәм аннан мәхрүм итү тәртибенә, шулай ук «Милли сәүдә маркасы» мәгълүмат билгесен куллану хокукын алуга карата таләпләргә 2 нче кушымта

«Милли сәүдә маркасы»
мәгълүмат билгесен куллану хокукына
таныклык

____________________________________________________________________________
(юридик затның яки индивидуаль эшмәкәрнең тулы исеме,

____________________________________________________________________ бирелде.
юридик адресы)

Бу таныклык белән ___________________________________________________ га
(оешма исеме)
Азык-төлек продуктларының сыйфатын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү мәсьәләләре буенча ведомствоара яраштыру советы карары (_____________ ____ номерлы беркетмә) нигезендә _________________________________________________
(азык-төлек продукциясенең исеме)
__________________________________________________________________________ га

«Милли сәүдә маркасы» мәгълүмат билгесен куллану хокукын бирү раслана.

Азык-төлек продуктларының сыйфатын
һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү мәсьәләләре
буенча ведомствоара яраштыру советы
рәисе _____________ ________________________
(имза) (Ф.И.Ат.ис.)

«__» _____________ 20__ ел

№ _____________________________

20__ елның «__» _____________ кадәр гамәлдә

______________________________